**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

25 июль 2014 ел № 7-16/т

Казань
шәһәре

***“Казан тармакара промышленность тимер юлы предприятиясе” ҖЧҖнең илтүче тимер юлында транспорт хезмәте күрсәтү өчен максималь чик тарифларны билгеләү турында***

“Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салу турында” 07.03.1995 № 239 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь 2010 468 №лы карары белән расланган карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. “Казан тармакара промышленность тимер юлы предприятиясе” ҖЧҖнең илтүче тимер юлында транспорт хезмәте күрсәтү өчен максималь чик тарифларны, түбәндәге карарның кушымтасына килештереп билгеләргә.
2. “Казан тармакара промышленность тимер юлы предприятиясе” ачык акционер җәмгыятенә илтүче тимер юлында транспорт хезмәте күрсәтү өчен максималь чик тарифларны билгеләү турында” 12.04.2013 № 7-9/т Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты карары 1нче кушымтасының 1нче пунктын үз көчен югалткан дип исәпләргә.
3. Түбәндәге карар рәсми нәшер ителгәннән соң ун көн узгач тулы көченә ия була.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитетының
25 июль 2014 ел № 7-16/т

“Казан тармакара промышленность тимер юлы предприятиясе” ҖЧҖнең илтүче тимер юлында транспорт хезмәте күрсәтү өчен максималь чик тарифлар

I бүлек. Максималь чик тарифлар

| № п/п | Уңайлык төре | Үлчәү берәмлеге | Максималь чик тариф, сум (ӨБС исәпкә алынмый) |
|---|---|---|---|
| 1. | Йөкне 3 км ераклыгына алып бару | 1 тонна | 73,18 |
| 2. | Йөкне 3 км зуррак булган ераклыкка алып бару (һәр км 1 тонна өстәп) | 1 тонна | 24,88 |

II бүлек. Башка шартлар

1. “Максималь чик тарифлары” Iнче бүлегендә каралмаган, промышленность тимер юлы транспорты тарафыннан күрсәткән хезмәт өчен тарифлар, 20.12.2001 № АН-104-р Россия Федерациясе транспорт Министырлыгы фәрманы белән расланган, промышленность тимер юлы транспорты күрсәткән хезмәт өчен тарифларны һәм җыемнарны формалауга караган Методик күрсәтмәләргә туры китереп, якларның үзара килешүе нигезендә билгеләнә.

2. Йөкне күчерү һәм төяү-бушату өчен түләү, заказ биречүдән күчерелгән йөкнең фактик авырлыгы өчен алына.

3. Түләүне алу өчен, йөкне күчерү ераклыгы километрларда түгәрәкләп алынып билгеләнә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештуры һәм җайга салу бүлеге